**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ДӘВЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2020 ел, 10 август №4

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 19 сентябрендәге «Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге территориясендә кулланучыларда эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру турында » 9 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларының һәм норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында, мәҗбүри таләпләре булган федераль башкарма хакимият органнарының кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда тикшереп тору чараларын уздырганда үтәлеше бәяләнгән норматив хокукый актларын юкка чыгару турында» 2020 елның 11 июлендәге, 1036 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарының 1 нче кушымтасындагы 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 19 сентябрендәге «Апас муниципаль районы Дәвеш авыл җирлеге территориясендә кулланучыларда эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру турында » 9 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

**Дәвеш авыл җирлеге**
**Башлыгы** **Т.Т. Хөсәенов**